БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«28» 06 2022 ел

**КАРАР**
№ 205

«Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтен капиталь ремонтлау өчен субсидияләр бирү турында» нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә һәм Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2008 елның 23 маендагы 197 номерлы карары белән (2020 елның 16 октябрендәге 302 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 322 номерлы, 2021 елның 6 февралендәге 75 номерлы үзгәрешләр белән) расланган «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтен капиталь ремонтлау өчен субсидияләр бирү турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- сайлап алуда катнашучылар экстремистлык эшчәнлегенә яки террорчылыкка катнашы булуы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралы таратуга катнашы булуы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булырга тиеш түгел.»;

1.2. 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.6 статья өстәргә:

«4.6. Субсидия акчалары хисабына, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаштыру әйберләрен сатып алганда (китерткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге башка операцияләр акчаларын алу максатларына ирешүгә бәйле операцияләрдән тыш, чит ил валютасын сатып алу тыела.»;

1.3. 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.7 статья өстәргә:

«5.7. Субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү, шулай ук муниципаль финанс тикшерүе органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүләр өлешендә субсидияләр алучыларга

һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән затларга карата тикшерү субсидия бирүче бюджет акчаларының баш бүлүчесе (бүлүчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин